КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 12 декабрь г.Казань № 1312

Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең аерым дәүләт учреждениеләрен үзгәртеп төзү турында

Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү тармагы инфраструктурасын оптимальләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Авиатөзелеш районы халкын эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесен, «Вахитов районы халкын эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесен, «Киров районы халкын эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесен, «Мәскәү районы халкын эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесен, «Яңа Савин районы халкын эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесен, «Идел буе районы халкын эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесен (алга таба - Үзәкләр), «Казан шәһәре халкын эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесен (алга таба - Учреждение) Үзәкләрне Учреждениегә аларның эшчәнлегенең төп максатларын, әлеге учреждениеләрнең җыелма штат санын һәм Учреждение исемен саклап калып, кушу рәвешендә үзгәртеп оештыру турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Учреждениене гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы гамәлгә ашыра дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

эш көннәрендә исәпләнә торган 90 көн эчендә бу карарның 1 пунктында күрсәтелгән учреждениеләрне үзгәртеп оештыруга бәйле булган, законнар белән каралган чараларны тәэмин итәргә;

юридик затларның бердәм дәүләт реестрына Учреждение Уставына үзгәрешләр кертүне тәэмин итү турында язма кертелгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә;

эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Үзәкләргә оператив идарә хокукында беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен алга таба файдалану турындагы тәкъдимнәрне, шулай ук күчемсез мөлкәт объектларына техник документацияне Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына кертергә;

бу карарның 1 пунктында күрсәтелгән учреждениеләрне үзгәртеп оештыру чараларын үткәрү чыгымнарын тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы» ведомствосы буенча халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре эшчәнлеген тәэмин итү чыгымнары өлешендә каралган акча чикләрендә финанслауны тәэмин итәргә;

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән учреждениеләрне үзгәртеп төзү нәтиҗәсендә азат ителә торган хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тәкъдим иткән исемлек нигезендә, элек Үзәкләргә беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен эш көннәрдә исәпләнә торган 60 көн эчендә законнарда билгеләнгән тәртиптә Учреждениегә тапшыруны тәэмин итәргә.

5. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2021 ел, 16 февраль, 84 нче карарына үзгәрешләр кертү хакындатәкъдимнәр кертергә.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин